КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 декабрь г.Казань № 1592

Зеленодольск муниципаль районында
җир кишәрлеген бер категориядән
икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Зеленодольск муниципаль районында урнашкан 23,5925 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:20:090801:1097 кадастр саны белән спорт белән шөгыльләнү мәйданчыгын урнаштыру максатларында махсус саклана торган территорияләр җирләре һәм объектлар категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин